**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АК-ТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.r

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

_______________ | № ________

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының
хәрби комиссариатында хәрби-табиб комиссиясе эшен оештыру турында

Россия Федерациясе Президентының «Хәрби комиссариатлар турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 07 декабрендәге 1609 номерлы Указы, «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хәрби-табиб экспертизасы турындагы Нигезләмәне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 04 июлендәге 565 номерлы карары нигезендә, контракт буенча хәрби хезмәткә керүче гражданнарга карата хәрби-табиб экспертизасы мәсьәләләре буенча карарлар кабул итү, алар үтәргә теләк белдергән, хәрби үзәкләрдә һәм белем бирү оешмаларында хәрби әзерлек узучы һәм узу теләген белдергән, мәгариф оешмалары каршында хәрби әзерлек узучы һәм мәгариф оешмаларын тәмамлаучы хәрби кафедраларда (хәрби белем бирү факультетларында) үткән, хәрби җыеннарга чакырылганда Россия Федерациясе Хәрби Көчләренең мобилизацион резервларына керүче һәм анда булучы гражданнарны хәрби әзерлек узучы гражданнарга карата карарлар кабул итү максатыннан, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Запаста булган һәм контракт буенча хәрби хезмәткә керүче гражданнарның, хәрби җыеннарга чакырыла торган гражданнарның, училищеларга һәм хәрби-уку йортларына керүче, хәрби-табиб экспертизасы турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре запасында булган гражданнарның яраклылыгы турында нәтиҗә чыгару хокукы белән хәрби-табиб комиссиясен төзергә.

2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы хәрби комиссарының 2023 елның 02 ноябрендәге 66 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы хәрби-табиб комиссиясенең төп һәм резерв составын расларга.

3. Актаныш муниципаль районының запаста торучы һәм контракт буенча хәрби хезмәткә керә торган гражданнарын медицина тикшерүе уздыру өчен «Актаныш район үзәк хастаханәсе» ДАССУен (килешү буенча) җәлеп итәргә.

4. Гражданнарны хәрби хезмәткә чакыру чорында, «1997-2006 елларда туган гражданнарны 2024 елда хәрби хезмәткә чакыруны үткәргәндә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы чакырылыш комиссиясенең эш планы» белән расланган составта күрсәтелгән гражданнарны медицина тикшерүе үткәрү өчен кирәкле табиб-белгечләрне бүлеп бирергә.

5. «Актаныш район үзәк хастаханәсе» ДАССУ баш табибына тәкъдим итәргә:

табиб-белгечләрне һәм урта медицина персоналын РФнең 1998 елгы 53-ФЗ номерлы «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында»гы законы нигезендә, бүлеп бирергә;

- медицина комиссиясе эшендә катнашкан, медицина тикшерүен уздыру чорына төп эш урыны буенча хезмәт хакын саклап калып, төп эштән азат итәргә;

- табиблар булмаганда, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау Министрлыгы белән аларны башка медицина учреждениеләреннән бүлеп бирүне килештерергә;

- медицина комиссиясен кирәкле медицина-санитария мөлкәте белән тәэмин итәргә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хәрби-табиб экспертизасы турындагы нигезләмәне раслау турында» 2013 елның 04 июлендәге 565 номерлы карары нигезендә; - медицина тикшерүе узган чорда югарыда күрсәтелгән гражданнарга нәтиҗәләр бирү белән кирәкле тикшеренүләр оештырырга һәм уздырырга;

-стационар тикшерү өчен «Актаныш район үзәк хастаханәсе» ДАССУнә 2 койка-урын бүлеп бирергә, бу максат өчен иң җаваплы табиб-белгечләрне беркетергә һәм тулы һәм сыйфатлы тикшерүне тәэмин итәргә;

- дәвалау-профилактика учреждениеләре гаебе белән гражданнарны тикшерүне нигезсез озакка сузу очраклары булганда, кичекмәстән хәбәр итәргә һәм аны тәмамлау өчен конкрет чаралар күрергә.

6. «Запаста торучы һәм контракт буенча хәрби хезмәткә керә торган гражданнарны медицина тикшерүе уздыру өчен штаттан тыш даими рәвештә эш итүче хәрби-табиб комиссиясе төзү турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 10 ноябрендәге ПР-235 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны, килешү буенча, Актаныш районы хәрби комиссарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкче Р.А.Ильясов